**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ҖӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР

2020 елның 27 феврале № 183

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 июлендәге 72 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында «Интернет» челтәрендә урнаштырыла торган мәгълүмат исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге № 8-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2015елның 16 нчы январындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Олы Җәке авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге Советының 2017 елның 17 июлендәге 72 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының «Интернет» челтәрендәге эшчәнлеге турында мәгълүматлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. IV бүлегендә 26 пунктны төшереп калдырырга: «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында статистик мәгълүмат.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Олы Җәке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт (зур Җәке КФҮ бинасы), Каратмән авылы Клуб урамы, 23 нче йорт (Каратмән авыл клубы бинасы), Уразла авылы Дуслык урамы, 3 нче йорт (Уразлы авыл клубы бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Олы Җәке авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

**Олы Җәке авыл**
**җирлеге башлыгы, Совет рәисе:** **Ф.А.Фәйзуллина**